**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

Чернышевского ул., д.23, г.Лаишево 422610

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Чернышевский урамы, 23 нче йорт Лаеш ш. 422610

Тел: 8-(84378) -2-52-28 Факс: 8-(84378) -2-54-34

e-mail: Ispolkom.Laishevo@tatar.ru

2022 елның 14 марты 567 номер

# КАРАР

**Бима коттедж поселогы территориясен планлаштыру һәм ызанлау проектынраслау турында (кадастр номерлары 16:24:070801:2176, 16:24:070801:2177 булган җир кишәрлекләре).**

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 42, 45, 46 статьялары, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Уставына таянып, Территориянең тотрыклы үсешен тәэмин итү, планлаштыру структурасы элементларын (кварталлар, микрорайоннар, башка элементлар) бүлеп бирү, капиталь төзелеш объектлары урнашкан җир кишәрлекләренең чикләрен билгеләү, линия объектларын төзү һәм урнаштыру өчен билгеләнгән җир кишәрлекләре чикләрен билгеләү максатларында, 2021 елның 24 ноябреннән 29 декабренә кадәр уздырылган гавами тыңлаулар нигезендә карар бирәм:

1. Бима коттедж поселогы территориясен планлаштыру һәм ызанлау проектын расларга (кадастр номерлары16:24:070801:2176, 16:24:070801:2177 булган җир кишәрлекләре).
2. Әлеге карарны “Кама ягы”(«Камская новь») район газетасында, Интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб–адресы буенча һәм интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Порталында урнаштырылган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында- http://laishevo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).
3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

**Җитәкче** **А.А. Новиков**